Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2022 ел Менделеевск ш. №644

"Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне
торак белән тәэмин итү" ярдәмче программасы буенча
исәпкә кую һәм социаль түләү алуга хокук турында
таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 декабрендәге 837 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торакны сатып алырга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең электрон рәвештәге гарызнамәнең һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы гарызнамәнең дөрес булмавын ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән гарызнамәне электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников